ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.06.2021 г. Мөслим № 240

## Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм дәүләт торак программалары буенча торак урын бирү нормасы турында» 2006 елның 8 сентябрендәге 157 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына һәм «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 2 февралендәге 33 номерлы хатына таянып, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмен билгеләргә:

1.1. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен: 16 602,36 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен: һәр гаилә әгъзасына – 10 565,15 сум;

1.1.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә: һәр гаилә әгъзасына – 9 055,84 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 721 413,00 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 918 162,00 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 180 494,00 сум;

1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 1 573 992,00 сум;

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 1 967 490,00 сум;

1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 2 360 988,00 сум;

1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 2 754 486,00 сум;

1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 3 147 984,00 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р. Ф. Хантимеровка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**

*Татарстан Республикасы*
*Мөслим муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*2021 елның ______________*
*____ номерлы карарына*
*кушымта*

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләмен исәпләү**

Торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган муниципаль берәмлекләрдә – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма кеременең максималь күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС)** $^{-КП}$ **) / (0,25 х РС),** монда:

ПД – һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ – исәп күрсәткече;

ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2021 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән ставкасы елга 7,31%, ягъни 7,31/100/12=0,006 – айга);

КП – кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2021 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән вакыты 221,4 ай);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;;

0,25 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 2 февралендәге 33 номерлы хаты нигезендә 2021 елда Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 21 861,00 сум тәшкил итә.

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләмен исәпләү

| НП - торак урынының нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - Кредит буенча айлык процент ставкасы, (уртача еллык – 7,31%) (7,31/1 | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. | ПД - керемнең иң чик күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 00/12) | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 33 | 721413,00 | 1 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 0,25 | 16602,36 |
| 42 | 918162,00 | 2 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 0,5 | 10565,15 |
| 54 | 1180494,00 | 3 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 0,75 | 9055,84 |
| 72 | 1573992,00 | 4 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 1 | 9055,84 |
| 90 | 1967490,00 | 5 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 1,25 | 9055,84 |
| 108 | 2360988,00 | 6 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 1,5 | 9055,84 |
| 126 | 2754486,00 | 7 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 1,75 | 9055,84 |
| 144 | 3147984,00 | 8 | 21861,00 | 0,006 | 221,4 | 0,7 | 2 | 9055,84 |